ЯҢА КӘНӘФИ

Тимур Сөләйманов һәм Эдуард Вафин башка вазыйфаларга билгеләнде

> 2

ПАР ТУГАННАР

Дүрт игезәк әнисе Ләйсән Гыймаева балаларын ничек тәрбияли?

> 3



КУЯНГА – ЮЛ!

Минзәлә районында яшәүче куянлыларның хәлләрен сораштык

> 4

ЯЛДАН СОҢ

«ВТ» белгечләрдән эш һәм уку режимына кайту серләрен белеште

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 2 (28969) | Сишәмбе | 10 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

vk.com

КЫШ КЫШЛЫГЫН ИТТЕ

РЕСПУБЛИКАДАГЫ АНОМАЛЬ СУЫКЛАР НӘРСӘСЕ БЕЛӘН ИСТӘ КАЛА?

Сездә ничә градус салкын? Яңа ел ялларының соңгы көннәре гел шундый сораудан башланды. Якының белән аралашсаң да, «Ватсап»тагы авыл, эш төркемнәрен ачып карасаң да, сүзнең башы әнә шуңа барып тоташа. Чатнама кышкы суыкның үзәккә үтүе бер хәл. Кызганыч, зәмһәрир салкынның аянычлы нәтиҗәләрен дә барларга туры килде. Берәүләрнең өйдәге сулары катса, икенче берләре утсыз тилмергән. Газ шартлау, сөрем газыннан агулану очраклары да күзәтелде.

Чаңгыда йөрер чак

Яңа Чишмә районының Зирекле авылында яшәүче Сәләховларны ул яктан Ходай саклаган. Аскы урамнарда яшәүчеләрне су катып тилмерткәндә, аларның хуҗалыгына салкыннан андый-мондый зыян килмәгән. Хуҗабикә Әлфия ханым сүзләренә караганда, кичә аларда иртүк терекөмеш баганалары 40 градус салкын күрсәткән. Аскы урамнарда –45 градуска ук төшкән.

– Ишекләр бозланып катты инде. Салкыннан башка андый-мондый зыян күрмәдек, шөкер. Бөтен кеше, салкыннан туйдык инде, мондый хәлнең булганы юк иде, дип шакката. Бу фикер белән бер дә килешмим. Мондый чатнама салкыннар элегрәк тә күзәтелә иде бит инде. Бик озакка китмәсә, бер куркынычы да юк. Салкыннан куркып торган юк. Рәхәтләнеп чаңгыда йөрим, – дип шаккатырды укучыбыз.

Узган көндә Татарстанда ел башыннан алып икенче тапкыр шторм кисәтүе игълан ителде. Шуңа бәйле рәвештә республикада урамда уза торган бәйрәм чаралары кичектерелде, шугалаклар ябылды. Татарстан Гидрометеоүзәге фаразлары буенча, республикада һава температурасы урыны белән –41 градуска җитә. Шул рәвешле бу көннәрдә кыш кышлыгын итә. Актаныш районының Зөбәер, Әгерҗе районының Көчек авылларында да һава температурасы бу көннәрдә –45 градус тирәсендә тирбәлә. Башкортстанда яшәүче укучыларыбыз арасында: «Бездә 50 градус салкын», – дип хәбәр итүчеләр дә булды.

Көтелгән, әмма озаграк

КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, Казанда мондый аномаль салкыннар соңгы тапкыр 36 ел элек күзәтелгән. Бүген башкалада уртача һава температурасы климатик нормадан 18–19 градуска түбәнрәк. Белгечләр моны республикага Арктик циклон үтеп керү белән бәйләп аңлата.

– Чатнама салкыннар узган атнаның шимбәсендә башланды. Алар сишәмбегә кадәр дәвам итәчәк, – ди белгеч.

Переведенцев сүзләренә караганда, чәршәмбедән республикада көннәр акрынлап җылына башлаячак. Атна ахырына инде уртача тәүлеклек температура климатик нормага якынлашыр дип көтелә.

Балтач районының Яңгул авылында яшәүче «халык синоптигы» Әмир Шәрәфиев бу көннәрдә күзәтелгән салкыннарны көтелгән хәл дип атый. Хәтерләсәгез, узган саннарыбызның берсендә, Раштуа бәйрәмендә көннәр кисәк суытачак, чын кыш киләчәк, дип фаразлаган иде ул.

– Раштуа бәйрәмендә мондый салкыннар күзәтелү – гадәти хәл. Әмма башка елларда ул ике-өч көннән дә артмый иде. Быел озаккарак сузылды. 19 гыйнвардан соң ел да «крещение суыклары» да була. Раштуа суыклары озаккарак сузылгач, быел алар да соңрак башланачак. Бу салкыннардан куркырга кирәкми. Алар аркасында быелгы уңыш бик яхшы булачак. Хәзерге чатнама салкыннар арыш башак тутырган чорга туры килә, – ди Әмир абый.

Хәтерләсәгез, узган ел кыш азагында кышның «кәефе» бозылып алды. Февраль урынына – март, март урынына февраль килде. Нәтиҗәдә яз соңарды. Быел исә кыш азагы да, яз башы да уз урынында булачак, яз да вакытында киләчәк, дип фаразлый Әмир Шәрәфиев.

Күзәтеп торасы

Татарстан буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, бәйрәм ялларында республикада барлыгы 14 янгын очрагы теркәлгән. Алар, нигездә, электр җиһазларын, мичләрне дөрес кулланмау аркасында килеп чыккан. Ут белән сак эш итмәү дә сәбәпче.

Елларда сөрем газы белән агулану очраклары да шактый күзәтелгән. Узган якшәмбедә башкаланың Киров районында берьюлы шундый ике очрак теркәлгән. Беренчесендә 12 һәм 5 яшьлек бала белән аларның 1941 елгы әбиләре зыян күргән. Батыршин урамында да сөрем газы белән агуланган өч кеше, шул исәптән 9 яшьлек малайны хастаханәгә озатканнар. Шул ук 8 гыйнвар көнне Азнакайда сөрем газы белән агуланган тулы бер гаиләне район үзәк хастаханәсенә алып килгәннәр.

Сөрем газы белән агулану очракларын булдырмас өчен һәрвакыт газ, мич һәм җылләткечнең төзек булуын тикшереп торырга кирәк, ди белгечләр. «Газ колонкалары һәм плитәләр булган өйләрдә сөрем газы белән агулану куркынычы зуррак. Мичкә ягып җылытыла торган өй һәм мунчаларга да яный мондый куркыныч. Ник дигәндә, утын тулысынча янып бетмәгән килеш мичне томаларга мөмкиннәр. Кышкы салкында өйдәге төтен юллары томаланмаганмы икәнлеген дә даими рәвештә тикшереп торырга кирәк», – ди белгечләр.

Ахыры 2 нче биттә >

Бәя бәйдән ычкынмасын

Җылылык бирү сезонында күпме ресурсның кулланылуын һәм аның өчен түләүнең дөреслеген аерым игътибар үзәгендә тоту кирәк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә шушы мәсьәләне күтәрде. Ул узган елның 1 декабреннән бөтен ил күләмендә торак-коммуналь хезмәтләр бәясенең уртача 9 процентка үсүен искә төшерде. «Республикада яшәүчеләргә декабрь ае өчен яңа тарифлар буенча счетлар килә башлады да инде. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, районнар хакимиятләре башлыклары һәм тиешле оешмалар җитәкчеләренә ТКХ хезмәтләре бәясенең дөреслеген тәэмин итәргә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Барлык шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр буенча тикшерүләр оештыру шарт. Халыкка түләүләрнең үсү сәбәпләрен, республикада гамәлдә булган социаль ярдәм чараларын аңлату мөһим».

Президент басым ясап әйткәнчә, аз керемле кешеләр өчен торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча ташламалар каралган. Ул Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына субсидияләрне үз вакытында түләү бурычын йөкләде.

Фараз чынга ашсын

Республикада 2023 елда 4,5–5 миллион тонна ашлык җыеп алу күздә тотыла. Татарстан вице-премьеры – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров шулай дип белдергән.

Моннан тыш быел 1,8 миллион тонна шикәр чөгендере, 1,1 миллион тонна бәрәңге һәм башка яшелчә үстерү планлаштырыла. Май культуралары уңышы 600 мең тонна булыр, терлек азыгы 1 баш шартлы терлеккә кимендә 30 центнер күләмендә әзерләнелер, дип көтелә.

Биш мәктәп төзелә

Татарстанда быел биш мәктәп төзү күздә тотыла. Яңа мәктәпләр Казанда, Чаллыда, Арча һәм Тукай районнарында ачылачак. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, яңа елда республика алты илкүләм проектны һәм дүрт дәүләт программасын тормышка ашыра башлый. Татарстанда яңа мәктәпләр «Мәгариф» илкүләм проекты буенча төзеләчәк. Казандагы ике яшьләр үзәге өчен җиһазлар сатып алу, шулай ук Чүпрәле һәм Теләче районнарында спорт залларын ремонтлау да илкүләм проект хисабына башкарылачак.

Республика программасы кысасында – 37 мәктәп, «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасы буенча 31 оешма бинасын төзекләндерү көтелә.

Озын ял озак көттерми

Киләсе озын ял февраль ахырында булачак. Аның алдыннан – өч көнлек эш атнасы. Февральдә рәттән дүрт көн: 23–26 февральдә ял итәчәкбез. 24 февральдә ял итүебезнең сәбәбе – 1 гыйнвар ялының (быел ул якшәмбегә туры килде) шул көнгә күчерелүе.

Исегезгә төшерәбез: 2023 елга ял һәм бәйрәм көннәре календарен Россия Хөкүмәте 2022 елның августында бастырып чыгарган иде. Шулай итеп, быел Татарстанда атнасына биш көн эшләүчеләр өчен 244 эш көне булачак. Ял көннәре саны – 121, шул исәптән 17 бәйрәм көн.

Ышанмаска кушалар

Россиядә мобилизациянең дәвам итүе турындагы хәбәргә ышанасы түгел. Россия Президентының матбугат секретаре Дмитрий Песков журналистларга шулай дип белдергән.

«Гомумән, телеграм-каналларга әһәмият бирмәскә кирәк. Беренчел чыганак – Россия Президенты җитәкчелегендәге рәсми хакимият белдерүләренә генә таяну дөрес булачак», – дигән Кремль вәкиле.

Исегезгә төшерәбез: узган елның 21 сентябрендә Россия Президенты Владимир Путин өлешчә мобилизация турындагы указга кул куйды. 28 октябрьдә оборона министры Сергей Шойгу аның тәмамлануы турында хәбәр итте. Шуннан соң дәүләт башлыгы илдә мобилизацияне яңартып җибәрүгә бернинди дә сәбәпнең булмавы хакында берничә тапкыр әйтте.

Юл иминлеге

Җиде кат тикшер, бер кат кабыз

Гыйнварның беренче атнасында республика юлларында 47 юл һәлакәте теркәлгән. Ни кызганыч, аларда 7 кешенең гомере өзелгән. Машинасы салкынга бирешеп, юлда «катып калучылар» да бар. ЮХИДИ хезмәткәрләре бу көннәрдә, гомумән, ерак юлга чыкмаска киңәш итә.

Татарстан Дәүләт автоинспекциясе мәгълүматларына караганда, 1–7 гыйнвар көннәрендә республикада 47 юл һәлакәте теркәлгән. Аларда 77 кеше имгәнгән, 7 кеше һәлак булган. Куркыныч нәтиҗәгә китергән юл һәлакәтләренең күбесе каршы як полосага чыгуга бәйле, дип кисәтә ЮХИДИ хезмәткәрләре.

Бөгелмәдә юл фаҗигасендә берьюлы өч кеше үлгән. Юл һәлакәте 2 гыйнвар көнне Казан – Оренбург юлында чыккан. Әйтүләренә караганда, «Honda» машинасын йөртүче тизлекне чамадан тыш арттырган һәм, каршы як полосага чыгып, «Opel» автомобиленә бәрелгән. «Honda» машинасын йөртүче һәм аның пассажиры һәлакәт урынында ук җан биргәннәр. Зыян күрүчеләр арасында ике яшьлек сабый да бар. «Бала махсус утыргычта була», – дип тә искәртә ЮХИДИ хезмәткәрләре. Әмма өйгә исән-сау әйләнеп кайту өчен өлкәннәрнең юл кагыйдәләрен тиешенчә үтәве дә кирәк шул. Татарстан прокурорының өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев сүзләренә караганда, әлеге очрак буенча тикшерү эше башланган.

Әлмәт – Мөслим юлында килеп чыккан юл һәлакәте дә тетрәндерде. Фаҗигадә ике үсмер кыз һәлак булган. Алдан алынган мәгълүматларга караганда, «Hyundai» машинасын йөртүче тизлекне чамадан тыш арттырган һәм, каршы як юлга чыгып, «Toyota» автомобиленә бәрелгән. «Toyota» машинасындагы 17 һәм 19 яшьлек ике пассажир үлгән. Ике йөртүчене дә хастаханәгә озатканнар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Юлда уяулыкны югалтырга ярамый. Бигрәк тә, хәзерге кебек һава торышы кискен суыткан көннәрдә рульдә аеруча да сак булырга киңәш итәләр. Юллардагы бозлавык – бер хәл, салкында «тимер ат»ның үзен ничек тотачагын да алдан фаразлап булмый.

Елларда Казан – Ульян трассасында машинасы сүнеп калган йөртүчегә коткаручыларга шалтыратудан башка чара калмаган әнә. Гадәттән тыш хәл Буа районында килеп чыккан. Коткаручыларга машина йөртүче һәм бер пассажирны кайнар чәй белән сыйлап кына калмыйча, юлда «катып калган» автомобильне дә җылытырга туры килгән. Моңа охшаш хәл Казанда да килеп чыккан. Салкынга «тимер ат»лар да бирешә. ЮХИДИ хезмәткәрләре бу көннәрдә, гомумән, ерак юлга чыкмаска киңәш итә.

Рульгә утырырга туры килә икән, юлга кузгалганчы автомобильне яхшылап тикшереп чыгарга кушканнар. Бигрәк тә дизель ягулыгыннан файдаланучы «тимер ат»ларга суыклар куркыныч. Юлда гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта, **8(843)5-333-888** телефон номерына шалтыратып, Татарстан Дәүләт автоинспекциясенә хәбәр итәргә кушканнар. Юлларда сак булыгыз!

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Дәүләт Думасы Рәисе:

Чит ил компанияләренең 75,9 проценты Россиядә калды. Бу исә аларның безнең ил икътисады үсешенә ышанычы турында сөйли. Россиядән киткәннәрнең чыгымнары миллиардлар белән исәпләнә. Алар урынына үзебезнең предприятиеләр эшли. Әйтик, кием җитештерү күләме шактый артты. Шулай ук дарулар да күбрәк җитештерелә башлады. Эшләп тапкан акчаның Россиядә калуы һәм ил үсеше өчен кулланылуы мөһим.

(«Телеграм»дагы каналыннан)

РОССИЯДӘ – МАШИНАЛЫ БУЛУ



«РИА Рейтинг» белгечләре Россия төбәкләрендә күпме гаиләнең кредитка яңа машина сатып алып, аны куллану мөмкинлегенә ия булганын исәпләп чыгарган.

	Төбәк	Очсыз машина (0,9 млн сум) алучы гаиләләр %	Уртача бәядәге машина (2,5 млн сум) алучы гаиләләр %	Кыйммәтле машина (10 млн сум) алучы гаиләләр %
1	Ямал-Ненец АО	56,9	26,0	1,49
2	Чукотка АО	48,9	22,3	1,65
3	Магадан өлкәсе	44,2	18,3	1,40
4	Ханты-Манси АО	40,4	13,8	0,50
5	Ненец АО	38,1	15,5	0,55
6...	Мәскәү	37,3	17,1	1,61
...29	**Татарстан**	**14,6**	**2,7**	**0,16**
...84	Чечня	2,8	0,5	0,01
85	Ингушетия	2,5	0,5	0,01



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАШЛАНЫП КИЛҮЧЕ ЕЛ АВЫРЛЫКЛАРЫ

2023 елның беренче сәгатьләре санала башлауга, Халыкара валюта фонды рәисе Кристалина Георгиева яңа елга начар фараз бирде. Аның фикеренчә, Европа берлеге рецессиягә кереп батачак. Гомумән, өч эре икътисад: АКШ, Кытай һәм Европа берлеге бик нык акрынаячак һәм акрынаю берьюлы булыр, диелә ул игълан иткән белдерүдә. Фаразлары яңалык түгел, билгеле. Нефть бәясенә карап билгеләп була глобаль икътисадның торышын. ОПЕК+ илләренең «кара алтын» чыгаруны арттыруга аяк терәп каршы торуларына, Россия чималы сатылу чикләнүгә карамастан, баррель чагыштырмача түбән бәядә. Иң кызыгы: кыш уртасында Европада газга бәяләр төшә. Соңгысы, әлбәттә, континентта гадәттән тыш кыш җылы булу һәм җил станцияләренең күп энергия җитештерүләренә бәйле. Әмма шулай да…

Үткән елда Гонконгта торак сату 40 процентка кимегән. Андый хәл 2008 елгы кризиста гына күзәтелгән булган. Бу – дөньяда иң кыйммәтле торак базары булып саналган төбәк. Белгечләр Гонконг торак базарында түбәнәю 2023 елның урталарына кадәр барыр дип фаразлыйлар.

2022 елда топка кергән иң эре криптокомпанияләр 10 проценттан алып 50 процентка кадәр персоналларын эштән азат иткәннәр. Криптовалюталарның бәясе ничек төшүен, түнтәрелгән криптобиржалар турында без бер генә тапкыр язмадык. Спекулянтлар дистәләгән, йөзләгән, хәтта триллионлаган доллар акчасын югалтып өлгерде. Иң эре криптобиржа булган Binance (Кытай бизнесы) кыенлыклар кичерә. Соңгы бер ай эчендә ул 25 процент капиталын югалтты. Америкада түнтәрелгән криптобиржалар җитәкчеләрен мошенниклыкта гаепләп кулга алдылар. «Ватаным Татарстан» аерым язма багышлаган Сэм Бэнкман-Фрид та төрмә шулпасын эчеп карады. Дөрес, аны зур күләмдә залог түләтеп иреккә чыгардылар, әмма җинаять эше дәвам итә. Америка законнары буенча аңа гомерлек төрмә яный. Ләкин егет бик күп зур сәясәтчеләрне, шул исәптән Байденны да финанслаган. Шуңа да җиңелрәк җәзага өметләнә ала.

Bloomberg агентлыгы Кытайда COVID-19 сәбәпле үлемнәр күбәйгәнлектән, крематорийлар тулы дигән хәбәр таратты. Чикләүләр бетерелгәч, Кытай, чынлап та, коронавирус кочагына ауды. Үлемнәрнең төрле дәрәҗәдәге саннарын атыйлар. Астрономик саннар да күренә. Тикшереп була торган әйбер булмагач, без бер санны да китермибез. Әмма бер нәрсә ачык: пандемиягә каршы кытайча көрәш нәтиҗәле түгел, куркыныч хәтта. Миллионлаган кешене өйләрендә бикләп тоту иммунитетны тәмам бозып бетергән. Хәзер аларга барысы берьюлы чирләп, без үткән юлны зур тизлектә үтәргә туры киләчәк. Европада коронавирусның «кракен» дигән омикрон варианты тарала дигән хәбәрләр бар. Тиз хәрәкәт итә икән. Ләкин Көнбатышта беркем дә бикләнмәде, димәк, зур куркыныч янамый дип өметләник.

Яңа елның беренче зур фетнәсе дә аваз бирде. Якшәмбе көнне (бездә төн булганда) Бразилиядә элекке Президент Болсонару яклылар конгресс бинасын, Югары Судны яулап алдылар, Президент сараена бәреп керделәр. Гамәлдәге лидер Лула да Силва качып өлгерде. Ләкин армия аны яклый. Фетнә бастырыла башлады инде.

Россиядә

ИМПОРТНЫ АЛЫШТЫРУ ЗЫЯНЛЫ

Үткән ел ахырында Россия Үзәк банкының Тикшеренүләр һәм фаразлар департаменты икътисадчылары сәеррәк яңгырый торган бер нәтиҗә ясадылар: импортны алыштыру илдәге тормыш дәрәҗәсен түбәнәйтә, диделәр. Алар фикеренчә, импортны алыштыру хәтта нәтиҗәле булганда да, эшче көчләрне җәлеп итеп, икътисадка начар тәэсир ясый икән. Колакка сәеррәк ишетелә, билгеле, андый белдерүләр. Әмма аңлатып була аларның фикер сөрешен, рациональ орлыгын табып була. Үз кабыгыңа бикләнеп, ил эчендә бар нәрсәне үзең генә җитештерә башласаң, чынлап та, финанслау да күп таләп ителә, эшче көчләрне дә күп сорый, үзкыйммәте дә гаҗәп югары була. Без моның шулай икәнен узган елның март башында ук «Үзебезнекен үзебез ашасак, көчебез артырмы?» язмасында дәлилләп күрсәткән идек. Үзәк банкның тулы бер департаменты белгечләре, санкцияләр кертелеп, ун көн үткәнче үк без ясаган нәтиҗәне ел ахырында гына ясаганнар.

Үзебездә нәрсәнедер уңышлы җитештерү башка илләр белән кооперациясез генә була алмый. Кадагына кадәр үзең ясап, йорт салу мөмкин түгел. Бу – аксиома, егерме беренче гасырда исбатлауны таләп итми. Россиядә исә никтер моңа игътибар итеп бетермәделәр, шуңа күрә үзебезнеке дип саналган зурдан кубып тотынган проектлар да бушка әйләнә, бер урында таптана. Sukhoi SuperJet 100 дип аталган, башта импорт комплектлаучы детальләрдән җыелып, аннан үзебезнекеләргә күчеп җитештерелергә ниятләнгән пассажир очкычы бар бит әле. 2017 елда аны 33не җитештергәннәр, 2018дә –25не генә, елдан-ел кимеп, 2022 елда унга гына калган. Унысы да сатылмаган әле аның. Бик күп миллиардларны үзенә йоткан проект бу. Вакытында Матвиенко ханым, суммасын атап: «Самолетлар кайда?» – дип нәгърә орган «импортны алыштыру».

Җиңел автомобильләрне үзебез җитештерә башласак та нәкъ шундый ук хәлгә калачакбыз. Милли автомобиль союзы вице-президенты Антон Шапарин бу хакта: «Россия автосәнәгате иллюзиясе таралды, заводларның диварлары гына калды», – диде. «Москвич» автомобильләре чыга башлады, әлбәттә, әмма, әйдәгез, үзебезне үзебез алдамыйк: сүз бит «Москвич» логотибы ябыштырылган Кытай автомобиле турында бара.

Теоретик яктан бары тик үзебезнеке генә булган продуктлар җитештерү мөмкин ул мөмкинлеккә. Әмма аның өчен миллионлаган инженер, конструктор, башка белгечләрне берьюлы хезмәт базарына чыгарып тотырга һәм, алар җитештергән продукт бәясе сатып алырлык булсын өчен, аны йөз миллионлап җитештереп дөнья базарында сатарга туры килер иде. Дөнья базары әлегә безнең нефть һәм газ өчен дә бикләнеп ята. Шулай булгач, Үзәк банкның югарыда телгә алынган департаменты белгечләре ел буе калькулятор төймәсенә басып исәпләгәч ясаган нәтиҗәсе сәер яңгыраса да, дөрес. Без март аенда аны бармак бөгеп кенә дә исәпләп күрсәткән идек.

КЫШ КЫШЛЫГЫН ИТТЕ



Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Өйдә кешең булмаса…

Бу көннәрдә Татарстан мәктәпләрендә кышкы каникулны да озайттылар. «Салкын көннәр килү сәбәпле, уку расписаниесенә үзгәрешләр кертелде. Татарстанның күп кенә мәктәпләрендә кышкы каникул язгы каникул хисабына 2 көнгә озайтылды», – диелә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәрендә.

Билгеле булганча, аңа кадәр авыл мәктәпләрендәге башлангыч сыйныфларда дәресләр – 23 градус салкын булганда, шәһәр мәктәпләрендәге башлангыч сыйныфларда һәм авыл мәктәпләрендәге 5–9 нчы сыйныфларда 25 градус салкын булганда үткәрелмәве хәбәр ителгән иде. Министрлык мәгълүматларына караганда, шәһәр мәктәпләрендәге 5–9 нчы сыйныфларда –27 градус салкын, авыл мәктәпләрендәге 10–11 нче сыйныфларда 30 градус салкын һәм шәһәр мәктәпләрендәге 10–11 нче сыйныфларда 32 градус салкын булганда дәресләр булмый.

Дөрес, өйдә баланы калдырырга кеше булмаганда, ул элеккечә үк мәктәпкә укырга килә ала. Министрлык бу уңайдан да рәсми белдерү белән чыкты. «Өйдә баланы калдырырга кеше булмаса, белем бирү оешмасы аны бернинди һава торышына карап тормастан кабул итәчәк. Көннәр чамадан тыш салкын булуга карамастан, республика мәктәпләре, укытучылар тулы составта элеккеге режимда эшләячәк», – диелә хәбәрдә.

Җылытмый

Озын Яңа ел ялларында республикада өшүчеләр дә шактый булган. 31 декабрь – 9 гыйнвар аралыгында Татарстанның дәвалау оешмаларына өшү билгеләре белән 126 кеше мөрәҗәгать иткән. Шуларның 95ен хастаханәгә үк салырга туры килгән.

Яшерен-батырын түгел, зәмһәрир кышкы суык көннәрдә исерткеч эчемлекләр ярдәмендә җылынырга маташучылар да шактый була. Белгечләр исә моны зур хата дип саный. Бәйрәм ялларында теркәлгән өшү очракларына да нигездә әнә шул яшел елан гаепле, ди алар.

– Исерткеч эчемлек салкында организмны һич кенә дә җылытмый. Организмга эләккәч, ул киеренкелекне бетерә, кан тамырларын киңәйтә. Ул вак кан тамырларына тарала, шул рәвешле тән тиресе җылына. Әмма салкында ул бик тиз югала, – ди Республика клиник наркология диспансерының бүлек мөдире Дамир Ваһапов.

ГЫЙНВАР АЕНА ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

- ✓ Гыйнвар карсыз һәм суык булса, җәй коры һәм эссе була.
- ✓ Гыйнварда кар күп яуса, бураннар еш булса, җәй яңгырлы була.
- ✓ Гыйнварның икенче яртысы кояшлы торса, уңыш яхшы була.
- ✓ Сукыр тычкан оясыннан гыйнварда чыкса, май салкын булыр.
- ✓ Гыйнварда коры һәм суык булса, язын кар тиз эреп бетәр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

tatarstan.ru

Беренче үзгәрешләр

ТИМУР СӨЛӘЙМАНОВ һӘМ ЭДУАРД ВАФИН ЯҢА ВАЗЫЙФАГА БИЛГЕЛӘНДЕ

Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов үз вазыйфасыннан китте. Ул Татарстан Президенты ярдәмчесе итеп билгеләнде. Шулай ук элеккеге министр Бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең республика бүлеге җитәкчесе вазыйфасын да башкарачак.

Тимур Сөләйманов 2021 елның сентябреннән министр булып эшләде. Аңа кадәр министрның беренче урынбасары вазыйфасын башкарды. Хәер, Тимур Сөләйманов яшьләр арасында яңа кеше түгел. Ул Татарстандагы «Студентлар лигасы» президенты, «Сәләт» директоры буларак та таныш. Тимур Сөләймановның яңа вазыйфага билгеләнүе турындагы имеш-мимешләр узган ел ахырында ук таралды. Аны яңа кәнәфигә Татарстан Хөкүмәт йортында тәкъдим иттеләр. Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгын алга таба кем җитәкләячәге әлегә билгеле түгел. Әлегә бу вазыйфаны Тимур Сөләймановның беренче урынбасары Ренат Садыйков башкара.

Билгеле булганча, «Беренчеләр хәрәкәте» бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәте Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә узган ел оешты. Владимир Путин хәрәкәтнең күзәтү советын җитәкләде. Илбашы бурычны да зурдан куйды. Яңа хәрәкәт бөтен ил яшьләрен берләштерергә тиеш. Татарстанда егет-кызларны бер йодрыкка туплау белән Тимур Сөләйманов шөгыльләнәчәк. Яңа вазыйфадагы эшләре турында яңа билгеләнгән җитәкченең үзеннән сорадык:

– Хәрәкәт ул – кечкенәдән үк кеше тормышындагы кыйммәтләр системасын барлыкка китерүче әйләнәтирә мохит, – диде Тимур Сөйләманов. – Шәхес буларак үсеш нәкъ менә шуңа бәйле дә инде. Шунысы да мөһим: хәрәкәт эшендә балалар һәм яшьләр турыдан-туры үзләре катнашачак. Алар тәкъдиме белән мәктәпләрдә, көллиятләрдә, яшьләр үзәкләрендә Хәрәкәт клублары барлыкка киләчәк. Республиканың һәр районында иҗтимагый штаб оештырачакбыз.

Тимур Сөләйманов фикеренчә, «Беренчеләр хәрәкәте» берләштереп кенә калмыйча, үзаңны үстерүгә дә хезмәт итәргә тиеш.

– Хәрәкәтнең төп максаты мәктәптә, көллияттә, үсмерләр клубында, яшьләр үзәгендә, мәдәният йортында, спорт мәктәбендә, «Ютуб»та, «ВКонтакте»да, урамда, кыскасы, балалар булган теләсә кайсы җирдә аларның шәхси үсешенә ярдәм итүче уңайлы мохит булдырудан гыйбарәт, – диде Татарстан Президенты ярдәмчесе.

Куян елында яңа вазыйфага билгеләнгән тагын бер җитәкче – Эдуард Вафин. Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе яңа оешкан Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнде.

Инде хәбәр иткәнебезчә, әлеге федераль структура 1 гыйнвардан Россия Пенсия фондын һәм Россия Социаль иминиятләштерү фондын берләштерде. Эдуард Вафинның узган елның декабрендә «Ватаным Татарстан»да басылган әңгәмәсендә хәбәр ителгәнчә, моннан ары халыкка барлык төр социаль ярдәм бер урында – Социаль фондта күрсәтеләчәк. «Россия Пенсия фонды һәм Социаль иминият фонды берләшүдән гади халыкка берни дә үзгәрми диярлек. Киресенчә, моның уңайлы яклары күбрәк булачак. Киләчәктә, бер түләү килде, ә икенчесе юк, дип борчыласы да булмаячак», – дип сөйләде идарәче.

Эдуард Вафин Пенсия фондында һөнәри эшчәнлеген 2000 елда икътисад бүлегенең әйдәп баручы белгече вазыйфасында башлаган. 2016 елның мартында Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе итеп билгеләнде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БЕРНИЧӘ КӨН КУРКЫНЫЧ ТҮГЕЛ

Мөнәсәбәт

«Кыш салкын була инде ул», – дисәләр дә, алдан ук аномаль салкыннар килә дип куркытулар да үз эшен эшләде бугай, соңгы вакытта бөтен сөйләшүязышу шушы салкыннар тирәсендә булды. Иртән күзне ачуга, телефонга смс килә: «Сездә ничә градус? Бездә ...»

Юкса, 30–40–45 градуслы салкыннар безнең якларда беренчесе түгел. Нигәдер шул аномаль сүзен өстиләр дә кеше күңеленә шом салалар. Әле моннан ничә еллап элек кенә Татарстанда һава температурасы айга якын кырыктан түбән булды. Салкын циклон безнең төбәктән чыкмый тилмертте. Башка бөтен күршеләрдә җылытып бетергәч тә, без әле кырык градустан түбән салкында тилмердек. Минус 44 тә булды, 47 дә. Хәтерлим әле: ул елны, ниһаять, җылыта башлады, 38гә менде (дөрес, сөйләшкәндә төште дип сөйләшәбез), диешкән идек. Салкыннарның берничә көн генә булуы куркыныч түгел, менә шулай айларга сузылса, ул чакта инде аномаль хәл дияргә дә буладыр.

Дөрес, куркытканга карап, бу көннәрдә авылларда да әллә ни әзерлек чаралары күрмәдек анысы. Элекке кебек, бәрәңгеләр өши күрмәсен дип, өй тирәләрен тәрәзә төбенә кадәр карга күмүчеләр дә, бәрәңге өстенә иске юрган төшереп ябучылар да булмагандыр (элек әле алай да бәрәңгесе өшегән кешеләр була иде). Мал-туарны да җылы бура-абзарларга күчерәсе юк, алар ел әйләнәсе җылытылган торакларда хәзер. Ашаулары мул, туклыклы, җылы су проблема түгел… Эт-мәче, кош-кортларны да хуҗалары бу чорда тәмлерәк ашатырга тырыша. Асларына да салам-печән чүпләрен гадәттәгедән калынрак тарата. Авылның һәр җан иясе кайгыртулы, кышкы салкыннарга әзер димәкче булам.

Өйләрне җылыту өчен дә утын-күмернең куәтләрәген, яхшырак яна торганын дип сайланасы юк, шөкер. Газ кергәнче менә болары кышкы салкыннарда беренче номерлы проблема иде. Яхшы сыйфатлы күмергә тиенү бик авыр. Өстәвенә мескен өлкәннәр мондый салкыннарда көн-төн мич ягу белән мәшгуль иделәр, күмер мичен сүндермичә, төн буе ягып, көненә ничә тапкыр утлы күмерен түгеп җәфаландылар… Моны күреп үскән безнең буын шуңа күрә дә, мондый салкыннарда газ, электр гына бетмәсен, хәвеф-хәтәр булмасын, дип тели.

Дөрес, салкыннарда өстәмә саклык чараларын күрү бик кирәк. Әнә авыл җирлеге башлыгы «Ватсап»тагы авыл төркеменә газ оешмасы хезмәткәрләренең кисәтүен җибәрде: «Мондый салкыннарда юллыклар бозлана, шул сәбәпле, газ мичләре юллыкларының тарту көчен көнгә берничә тапкыр тикшереп торыгыз», – диелә ул хәбәрдә. Кирәкле кисәтү. Сөрем газы белән агулану очраклары турында ишетеп торабыз. Шулай ук тагын бер мәрхәмәтлесе: «Су торбаларыгыз катмасын дисәгез, төнгә краннарыгызны бераз гына ачык калдырыгыз», – дип киңәш язып салган. Монысы да файдага. Бер хуҗалыкка кергән торба туңып, аннан соң гомуми трассага күчүе, авылның калган очындагылар да язга кадәр сусыз утырган очраклар булгалап тора. Көздән бөтен кеше дә чарасын күреп бетерми шул.

Аномаль салкыннар дигәннән, зарланырга яраткан кешеләр һава торышының һәр көненнән моң-зар өчен мең дә бер сәбәп таба анысы. «Җәйге эсселәрдә белеп зарланмаганбыз икән, салкында бик яман», – ди андыйлар (җәен исә, бу сүзләрне киресенчә әйләндереп, кышын әле кат-кат киенеп тә була, эссесе бик кыен диячәкләр). Җил икән, бетмәгән җил ди, кар-бураннан да ямь тапмый, җепшек көн дә ошамый, салкыны да… Ә оптимистлар исә: «Кары да, яңгыры да, бозы-салкыны да булды, вәйт ичмаса быелгы кыш!» – дип кинәнә.

Мондый салкыннарда өлкәннәр исә өстәп, бер теләк тели: «Әҗәлләргә сабырлык бир, Раббым!»

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ҮЗЕ КИТТЕ, МӘШӘКАТЕ КАЛДЫ

Бәйрәм узгач

Сүзебез – чын чыршыларны урнаштыру турында. Тиздән, ә бәлки инде кайберәүләр бу эшне эшләп тә өлгергәндер, йорт яннарындагы чүплек савытлары чыршы, аларның ботаклары белән тулачак. Әле җитмәсә, «Русский Стандарт» банкы уздырган тикшерү нәтиҗәләре буенча, быел узган елгы белән чагыштырганда, чын чыршыга ихтыяҗ 86 процентка арткан, ә ясалмаларга, киресенчә, 16 процентка кимегән.

– Башка елларны ясалма чыршы куя торган идек. Быел, исенә һәм матурлыгына кызыгып, базардан чын чыршы алып кайттык, – ди Казанда яшәүче Гөлнар Абдуллина. – Чыннан да, өйдә бөтенләй башка төрле мохит булды. Үзебез дә, балалар да бик канәгать иде. Матур һәм хуш исле булса да, чын чыршының мәшәкате дә бар икән. Әллә бик уңышлы булмады, әллә үзе шундый туры килде, яңа елның беренче көннәрендә үк ылыслары коелып бетте диярлек. Аларны җыеп арыгач, үзе белән дә хушлашырга туры килде. Чыршыны йорт янындагы чүплек савытына чыгарып куйдык. Бәлки махсус урынга да илткән булыр идек, тик, беренчедән, аларның кайда икәнлекләрен белә алмадык, икенчедән, алар соң гына эшли башлый икән.

Экологлар зур чыршыларны чүплек савытларына ташлауга гомумән каршы. Беренчедән, алар эре калдык булып санала һәм махсус бункерларга җыелырга тиеш. Икенчедән, полигонга эләккән очракта, таркалып, һавага метан бүлеп чыгара. Әгәр инде кая да булса илтүнең бөтенләй бер җае да булмаса, ылыслы агачларны чүплекләргә тураклап салырга кирәклеген искәртәләр.

Шулай да иң яхшысы – чыршы, наратны эшкәртергә бирү. Чөнки чыршы калдыкларын эшкәрткәннән соңгы йомычкаларны паркларда ашлама буларак кулланалар, юлларга түшиләр, терлекләренә бирү өчен фермерларга тапшыралар, яисә зоопарктагы хайваннарга ризык буларак бирәләр яки асларына түшиләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Беркайчан да чыршыларны чүплеккә ташламагыз, кар өеменә тыгып китмәгез, – дигән «Парламентская газета»га бу уңайдан Дәүләт Думасының Экология, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирәне саклау комитеты рәисенең беренче урынбасары Владимир Бурматов. – Чынлыкта, чыршы бик файдалы, хәтта Яңа ел бәйрәмнәре узгач та ул әллә нихәтле файда китерә ала. Аның йомычкасын бик күп максатларда кулланырга мөмкин, ә ылыстагы матдәсе табигый антисептик буларак хезмәт итә».

Менә шулай, табигатькә файда китерәм, дисәгез, Яңа ел «кунагы»н шәһәрләрдәге чыршы җыя торган махсус урыннарга тапшырырга мөмкин. Әйтик, нарат, чыршы, пихтаны һәм аларның ботакларын Казанда «Мега» сәүдә үзәгенә керә торган юлда кышкы бульварда кабул итәләр. Аларны бирегә 9 гыйнвардан алып 25 гыйнварга кадәр китерергә мөмкин. Халыктан җыеп бетергәч, ылыслы агачларны йомычкага ваклаячаклар, аннан соң Горки-Әмәт паркындагы кышкы юлларга түшәячәкләр.

Идел буе экология компаниясе Казанда иске чыршыларны тагын Гадел Кутуй урамы, 160 адресы буенча да кабул итә.

Бу эшне ел саен Чаллыда да башкаралар. Биредә чыршыларны 31 гыйнварга кадәр Автосборочный проезд, 29/63 адресы буенча кабул итәләр. Теләге булган һәр кеше ылыслы агачларны алып килеп, махсус контейнерда калдыра ала. Аннан соң аларны Татарстанның фермерлык хуҗалыкларына тапшыралар, анда агачның ылыслары һәм кайрысы терлекләр өчен витаминлы азык була, кәүсәсе исә аска җәю өчен эшкәртелә. Шулай ук агачлар ягулык сыйфатында да кулланыла.

– Чыршыны тапшырганчы, уенчыкларны һәм мишураларны алырга кирәк. Һәм кешеләр чыршыны алып килгәндә кулланган пакет, кәгазь, бауларын да алсалар иде. Эре агачларны кисәкләргә бүлгәләү дә хуплана, – дип аңлаттылар безгә Идел буе экология компаниясендә.

Моннан тыш, ылыслы агачларны мичтә яндырырга яки ашлама буларак җиргә дә күмеп куярга мөмкин. Авылларда андый мәшәкать юк анысы. Күпчелек кеше аларны ваклап, утын итеп файдалана, кемдер терлекләренә, сарык һәм кәҗәләренә ризык итеп бирә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧАЛЛЫ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ ДИРЕКТОРЫ РӘСИМ ХАФИЗОВ:

«ТАМАШАЧЫНЫҢ ЗӘВЫГЫ ҮСТЕ»

Мәдәният

Чаллы театры февральдә 3 көнлек гастрольләр белән Казанга килергә җыена. Башкала тамашачысы Чаллы тамашачысыннан нәрсәсе белән аерыла? Яңа бинага күчү театр тормышын ничек үзгәрткән? Халыкка нинди спектакльләр кирәк? Болар хакында Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының башкарма директоры Рәсим ХАФИЗОВ белән сөйләштек.

:: Рәсим Рәхимҗанович, Чаллы театры берничә ел эчендә шактый зур үзгәрешләр кичерде. Иң зурысы – яңа бинага күчү театр тормышын ничек үзгәртте?

– Без әле дә зур үзгәрешләр юлында. Чаллыда яңа театр формалашып килә. Бина, репертуар, актерлар, тамашачы – барысы да үзгәрде. Кечкенә генә бинадан зур, зәвыклы, җиһазлау ягыннан матур бинага күчтек. Татар театрлары арасында иң яхшы биналарның берсе дип әйтсәм дә, ялгыш булмас. Әйе, театрның яңа урыны турында күп фикерләр булды. Кемдер шәһәрнең ерак җирендә урнашканы өчен сүкте, ә кемдер, киресенчә, ошатты. Минемчә, театр шәһәрнең иң яхшы урынында урнашкан. Безнең янәшәдә генә – Марат Бигишев исемендәге театраль парк. Анда тәүлек буе кеше йөри, яшьләр өчен спорт, балалар өчен уен мәйданчыклары бар. Парк белән театр бергәлектә эшли. Төрле бәйрәмнәр, театраль Сабантуйлар үткәрәбез. Безнең өчен идеаль урын бу. Без кайда гына булсак та, театрны, сәнгатьне яраткан кеше юлын табачак һәм киләчәк. Аллага шөкер, кеше йөри, тамашачыбыз көннән-көн арта.

:: Репертуарыгыз кайсы якка үзгәрде?

– Репертуар эчтәлек ягыннан да, техник яктан да үзгәрде. Кайбер спектакльләр элеккеге бинадан яңасына күчмәде. Бу төрле сәбәпләргә бәйле: әйтик, декорацияләрнең иске булуы, спектакльнең заман таләпләренә туры килеп бетмәве һәм башкалар. Театрыбызның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов алып барган репертуар сәясәте әкренләп үзгәрә бара. Спектакльләрнең дә, тамашачының да зәвыгы үсте. Тирән эчтәлекле, татар халкының яшәеше, үсеше, көнкүреше турында спектакльләребез күбәйде.

:: Ә тамашачы бу үзгәрешләрне ничек кабул итте?

– Тамашачы хәзер бөтенләй икенче. Артистлар яңаргач, алар да яңарды. Кеше хәрәкәтләнгән, йөргән саен яшәрә, диләр. Без үзгәрәбез, шуның белән бергә тамашачы да үсә. Аларга зәвыклы, уйландыра, фикер йөртә торган спектакльләр кирәк. Безнең театрга татарлар гына түгел, руслар, татар телен белмәгән төрле милләт вәкилләре дә бик күп йөри. Узган ел шәһәргә Япониядән, Германиядән килгән кунаклар да безнең спектакльләрне карады.

:: Театр яшьләр белән дә тыгыз элемтәдә. Әйтик, яңа бинада алар өчен «Яшьләр каурые» дигән коворкинг үзәге булдырылды.

– Әйе, театрга килүче яшьләребез белән бик тыгыз аралашабыз, алар белән төрле чаралар үткәрәбез. Хәзер моның өчен театрыбызда бик матур һәм уңайлы коворкинг үзәге дә бар. Яшь рәссамнар, язучылар, фотографлар, блогерлар килә, үз идеяләрен тәкъдим итә. Театрыбызда «Театраль педагогика» дигән яңа проект та эшләп килә. Хәсән Туфан, Фатих Кәрим кебек язучыларыбызның биографияләре буенча «Хәл бу ки» спектакльләре чыкты. Ул күбрәк яшүсмерләр, мәктәп укучылары һәм укытучылары, студентлар өчен кызыклы. Мәктәптә язучыларның биографияләрен өйрәнәләр, ә театрга килеп, әйтик, Хәсән Туфанны, аның тормышын үз күзләрең белән күрү – ул бөтенләй икенче әйбер.

:: Казанга кайсы спектакльләрегез белән киләсез? Гомумән, кеше иң яратып йөри торганнары нинди?

– Казан тамашачысы алдында уйнау безнең өчен – зур сынау, имтихан ул. Гастрольләргә иң «кассовый» спектакльләрне алып киләбез. Ул да булса, классик Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» җырлы-биюле спектакле. Анда бөтен труппа диярлек катнаша. Шулай ук халык бик яратып йөри торган «Капка» һәм «Болан» спектакльләре.

:: «Шәһәр.Нокта.Брежнев» спектаклен әйтмәдегез. Ул ни өчен алдырып китә алмады? Үзегезнең шәһәр турында бит.

– Алдырып китә алмады, дип әйтә алмыйм, аңа тамашачы йөри. Бу спектакльнең үзенчәлеге шунда: ул 3 сәгать 55 минут бара. Театр, гомумән, Чаллы өчен мондый тәҗрибә беренче тапкыр. Безнең тамашачы андый озын спектакльләргә ияләнмәгән әле.

:: Бу сезонда тамашачыларны тагын нинди премьералар көтә?

– Хәзер без чираттагы премьераны әзерлибез. Галиәсгар Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев бездә Антон Чеховның «Чайка» («Акчарлак») спектаклен куячак. Минемчә, бик кызыклы булачак. Тамашачылар инде: «Татар театрында Чеховны ничек күрсәтәсез?» – дип кызыксына башлады. Бу – алар өчен дә, безнең өчен дә үзенә күрә бер сынау. Әйтик, Казан тамашачысы өчен татар сәхнәсендә рус классигы әсәрен кую яңалык тудырмый, ул күпне күргән инде. Ә Чаллы тамашачысы өчен бу – зур яңалык, аны берникадәр селкетеп җибәрү.

Ләйсән САФИНА

ОНЫТЫЛМАС ЕЛЛАР

Милләттәшебез Ленинград блокадасын кичергән Сатирә Сәгъдиеваның табынга утырган саен күзләре яшьләнә, күңеле ярларыннан ташып тула. Камалышта татыган газапмихнәт, ачлык-ялангачлыкны онытырлыкмы! Өч елга якын дәвам иткән мәхшәр хатирәләре аны әле дә озата бара. 96 яшьлек Сатирә әбинең ташып торган яшәү көче, рух ныклыгы сокландырды.

– Ленинград – миңа бик якын, кадерле, газиз шәһәр, аны бернәрсәгә дә алыштырмыйм, халкы – каһарман, чолганышта бирешмичә, аннан чыга алды, – ди Сатирә әби.

Блокада аның йөрәгенә, бәгыренә уелган. Ленинград кичергән тиңдәшсез афәтне дулкынланып, йөрәге сулкылдап искә ала. Сатирә Сәгъдиева Нева елгасы буендагы калага ничек барып чыкканын сөйләде. Халыкның күпләп илнең төрле якларына индустрияне күтәрергә – завод-фабрикалар, ГЭС, ТЭЦлар төзергә чыгып киткән еллары. Буа районының Ташкичү авылыннан Садретдин белән Гатикә (ул – Наратбаш авылыннан) Зыятдиновлар язмышында Ленинград язылган булган. Гаилә башлыгы биредә – 5 нче электр станциясендә, тегү эшенә оста Гатикә исә тегү фабрикасында хезмәт куя. Гаиләдә дүрт кыз – Зәйнәп, Сатирә, Зәйтүнә, Гөлҗиһан үсеп килә. Әмма илдә сугыш чыгып, тормыш тәртибен, уй-хыялларны җимереп ташлый. Садретдин гаиләсе белән камалышта кала. Хәтердән җуелмас ул еллар… Кала халкы бомба астында да эшли: окоплар казу, йорт түбәләрендә кизү торулар, Нева елгасына суга йөрүләр дисеңме. Һәр көн җелеккә, бәгырьгә төшә. Ачлык, салкын үзәккә үтә. Ә яшәргә, эшләргә кирәк. Зыятдиновлар гаиләсе дә эшкә җигелә. Өлкән кыз Зәйнәп хәрби заводта – хисапчы, әти-әниләре дә көне буе эштә. Эшләгәннәргә 200 грамм ипи бирелә. Сатирәгә – 13 яшь, Зәйтүнә белән Гөлҗиһан аннан кечерәк. Язмыш бу гаиләне дә аямый: Сатирәнең бер сеңлесе үпкә кабарудан, икенчесе ачлыкка түзә алмыйча тоз ашап үлә.

– Сеңелләремне машинага төяп алып китеп, «туганнар каберлеге»ндә бер чокырга күмделәр, – дип искә ала ул.

Ашамыйча гына түгел, берничә көн су эчмичә дә торган көннәре күп була. Сатирә урманга барып, орлыклар, үлән тамырлары ашап хәлләнә. Тик барыбер 10 килограмм авырлыкка калган кыз тәмам хәлсезләнә, бирешә. Бәхетенә, таныш табиб ярдәм кулы сузып, кабыргалары беленеп торган хәлсез Сатирәне хастаханәгә салалар. Биредә кыз тернәкләнә төшә.

Якынча исәпләүләр буенча Ленинград камалышында 600 меңнән 1,5 миллионга кадәр кешенең гомере өзелгән дип санала. Аларның нибары 3 проценты гына шәһәрне бомбага тоту вакытында һәлак булган, калганнары ачлыктан интегеп үлә. Камалыш тарихы турында Питерда «Блокада сакчылары» музее сөйли. Биредәге һәр экспонатны еламыйча карарлык түгел. Иң тетрәндергәне – күгәреп беткән шул чордагы ипи кисәге. Ул кыерчык ипи тисә әле… Ә ипи карточкаң югалса, яшәү юк дигән сүз. Ачлыктан интегеп үлүчеләр язып калдырган хатларны тыныч кына уку мөмкин түгел. Бомба төшеп шартлаган тавышлар сискәндерә. Музейда авыр тойгы, хисләр камалышында калып, яшәүнең, тыныч көннәрнең никадәр кадерле икәнен аңлыйсың.

Сатирә әби үзе сөйли, күзендә исә – чык тамчылары. Сеңелләрен искә алганда, гаепле кеше сыман аларның фотосурәтләрен сыйпый. Блокада михнәте аның әле дә җанын кыйный. Ладога күле аша «тормыш юлы» ачылган көнне гомерендә иң бәхетле мизгел дип саный. Кыз әлеге юлны чыкканда, бомба төшеп, баш мие селкенә. Бар да артта кала… Садретдин гаиләсе белән туган якларына кайта.

Сугыштан соң тагын да авыр еллар. Зыятдиновлар авыр хатирәләргә карамастан, җаннарына якын Ленинградны күтәрергә дип янә бирегә эшкә килә. Ә алар яшәгән фатир башка гаиләгә бирелгән булып чыга. Гаилә башлыгы тырыш хезмәт куеп янә фатир ала. Сатирә дә кул арасына керә – «Ломо» оптика-механика берләшмәсендә фотоаппаратлар ясый. Аның кулыннан нинди генә маркалы фотоаппарат узмый, шул рәвешле бу хезмәткә ул дүрт дистә ел гомерен бирә.

Кияүгә чыгып, ире Рәкыйп белән уллары Равилне тәрбиялиләр. Тырыш гаилә бакча тотып, мул тормышта яши. Уллары дә үзләренә охшаган, тырыш. Ул улы Эмильне дә югалып калмаслык, авырлыкларга бирешмәслек, тормышта үз урынын табарлык итеп тәрбияли. Әтисен генә түгел, апасы Зәйнәп, сугыш ветераны Исмәгыйль агасын да шәригать кануннарынча соңгы юлга озата, каберләрен карап тора, йола-гадәтләрне үти.

Сәгъдиевләр тормышында тыныч вакытта сугыш белән бәйле бер вакыйга була. Петроград районындагы фатирларын сатып, башка йортка күченәләр. Алар фатирына күченүчеләр капиталь ремонт ясаганда бала бүлмәсендәге дивардан сугыш вакытында кысылып калган снарядка юлыга. Аны махсус белгечләр чакыртып алалар.

– Ул фатирда шактый ел гомер иттек, улыбыз шул бүлмәдә үсте. Ә бит аның теләсә кайсы вакытта шартлау куркынычы булган, – ди Сатирә әби.

Ветеран улы, килененең ныклы игътибарында көн итә: урын-җире чиста, яхшы мөгамәлә, тәрбиядә. Шуңа да яшисе килеп гомер итә. Сеңелләре гомерен дә яши бит ул. Тик күңелен бүгенге вакыйгалар борчый. «Вакытсыз үлемнәр, җимерелүләр булмасын, камалышлар кабатланмасын, ил-көн тыныч торсын», – дип тели ул.

Бисмилласын әйтеп, табындагы ипи валчыгының бөртеген дә калдырмыйча җыеп ала да ул еллардагы мәхшәрне әкрен генә хәтер янчыгыннан бушатуын дәвам иттерә Сатирә әби. Вакыт узса да, онытылмаган ул еллар…

Рәзимә КАШАПОВА

ДҮРТ ИГЕЗӘК ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ ЛӘЙСӘН ГЫЙМАЕВА:

«Балаларга тырнак белән дә чиерткән юк»

Берьюлы дүртне тапкан дип аптырый күрмәгез тагын! Ике пар игезәк. Баулы районының Татар Томбарлысы авылында яшәүче 47 яшьлек Ләйсән Гыймаева башта – игезәк кызлар, аннан алты елдан соң малайлар алып кайткан. Өч ай элек Ләйсән белән Рамил иллегә дә җитмәгән килеш әби-бабай булган. Беренче оныклары туган икән. Әмма картаерга ашыкмыйлар: игезәкләр янында аларның энергияләре ике генә түгел, дүрт тапкыр арта.

Рамил «Берлек» совхозында – механизатор. Ләйсән Әлмәт сәүдә техникумын тәмамлап, хисапчы булып эшләгән. Хәзер авылда почта бүлеге җитәкчесе вазыйфасын башкара.

– Кияүгә 20 яшьтә чыктым. Бер елдан Радмир исемле беренче балабыз туды. Хәзер аңа 26 яшь. Өйләнеп, гаиләсе белән Казанда яшиләр. Өч ай элек беренче оныгыбыз туды, – ди Ләйсән Гыймаева. – Икенче улыбызга Радэль дип исем куштык.

Ике малайдан соң кыз көтә алар. Хатын-кызга өй эшләрендә булышырга ярдәмче кирәк бит. Аллаһы Тәгалә бу бүләкне икеләтә арттырып биргән. Беренче игезәкләре Адэлина белән Алинә 10 нчы сыйныфта укый. Ансэль белән Адэльны 36 яшьтә алып кайта Ләйсән. Егетләргә 10 яшь.

Тик Ләйсәннәр нәселендә игезәкләр дөньяга китерү сирәк хәл түгел. Арада Ләйсән кебек икешәр парны тапканы да бар.

– Игезәкләр су тамчысы кебек бер-берсенә охшамаган. Аларның кыяфәтләре дә, холыклары да төрлечә. Берсе шаянрак, икенчесе тынычрак. Буйлары да шулай: кемдер озынрак, кемдер кыскарак. Шуңа күрә аера алмыйча әле, – ди 6 бала әнисе. – Игезәкләр тәрбияләү җиңел түгел. Берсе уянса, икенчесе дә уяна. Әмма берсе дә елап үзәкне үтмәде. Яшермим, барысында да ничек җитешермен икән, дип борчылган чаклар да шактый булды. Киендерү, мәктәпкә әзерләү өчен чыгымнар да икеләтә китә. Шөкер, күп мәшәкатьләр артта калды инде. Кечкенә чакта кыен булса да, аның каравы хәзер бик рәхәт. Безнең өйдә күңелле. Игезәкләр табуым белән горурланам. Мондый бәхет бар хатын-кызга да эләкми.

Игезәкләрне үстерү үзе үк күңелле. Уенчык, кием алсаң да, бер төрлене алырга кирәк. Әмма, үскәч, бер-берсен кабатларга яратмыйлар икән. Бигрәк тә кызлар.

– Һич югы төсләре белән булса да аерылып торасылары килә. Әмма бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Кунакка да аерым йөрмиләр. Бергә йоклыйлар, ашыйлар, бергә китап укыйлар, өй эшләрен башкаралар, – ди Гыймаевлар.

Адэлина белән Алинә имтиханнарга да бергәләп әзерләнә. Киләсе елда БДИ тапшырасылары бар. Мәктәпне тәмамлагач, укырга да бергә китмәкчеләр. Исәпләре – дизайнер яки менеджер булу. Тик анысын хәл итеп бетермәгәннәр әле.

Тәрбия турында да сораштык. Монда бит бер генә түгел, берьюлы ике баланы тыңлатырга кирәк.

– Балалар тәртипле булсын, дөньясын онытып телефонда утырмасын өчен, кечкенәдән эшкә өйрәтергә кирәк. Без шулай тырыштык. Эштән кайтуга өйне җыештырып, гөлләргә су сибеп, идәнне юып куялар. Кызларның тагын бер елдан укырга чыгып китәселәре бар. Бар ризыкны да әзерләргә өйрәттем. Улларыбызның зурлары әтиләре белән техника янында кайнашып үсте. Тракторда да йөрделәр, комбайн ярдәмчеләре булып та эшләделәр. Төпчек булгач, кечкенәләрне иркәрәк. Тик алары кечкенәрәк шул әле, – ди хуҗабикә.

Алар өчен әни дә, дус та, психолог та ул. Ләйсән ханым әйтүенчә, балага тиктомалдан кычкырырга кирәкми. Аның әйтер фикерен ахырга кадәр тыңлап, аннан киңәшеңне бирсәң, бик яхшы аңлыйлар. Әлбәттә, түземлек кирәк. Мәктәп хәлләрен сорашып, өй эшләрен тикшереп, барысын да контрольдә тота икән. Әти-әни назын тойган балалар үзләре дә җавапны җылылык белән кайтара.

Сәрия МИФТАХОВА

Гыймаевларның шәхси архивыннан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 декабрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Конституциясенә (2002 елның 19 апрелендәге 1380 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9 – 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 3 – 4; 2003, № 9 (I өлеш); 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2010, № 3, № 11; 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 бүлек. **Татарстан Республикасы Рәисе**»;

2) 89 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«89 статья

1. Татарстан Республикасы Рәисе дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты була.

2. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының исеме – Татарстан Республикасы Рәисе.

3. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының әлеге статьяның 2 өлешендә каралган исеме Татарстан Республикасы Конституциясенә исемгә карата тиешле таләпне кертә торган үзгәрешләр үз көченә кергәннән соң сайланган Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затына карата кулланыла.

Татарстан Республикасы Конституциясенә исемгә карата тиешле таләпне кертә торган үзгәрешләр үз көченә кергәнче үткәрелгән сайлаулар нәтиҗәләре буенча вазыйфасына керешкән Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты, үз вәкаләтләрен үтәүне туктатканчы, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә әлеге зат сайланган иң югары вазыйфаи зат вазыйфасы исемен саклап кала.»;

3) 124 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Россия Федерациясе Конституциясен үзгәртүгә бәйле рәвештә, шулай ук законлы көченә кергән суд карары нигезендә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы закон Татарстан Республикасы Конституциясенең 123 статьясы таләпләрен исәпкә алмыйча кабул ителә һәм, аның өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге, кимендә өчтән икесе, тавыш бирсә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән дип санала.».

2 статья

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасының Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясындагы 2 өлешендә каралган исеме әлеге Закон үз көченә кергәннән соң сайланган Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затына карата кулланыла. Әлеге Закон үз көченә кергәнче үткәрелгән сайлаулар нәтиҗәләре буенча вазыйфасына керешкән Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты, үз вәкаләтләрен үтәүне туктатканчы, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә әлеге зат сайланган иң югары вазыйфаи зат вазыйфасы исемен саклап кала.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 31 декабрь
№ 109-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының фәнни потенциалын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең химия һәм химия технологияләре бүлекчәсе академигы-секретаре, президиумы киңәшчесе – баш белгече, «Идел буе углеводород чималы фәнни-тикшеренү институты» гавами булмаган акционер җәмгыяте директоры **Мазһаров** Әхмәт Мазһар улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың урман хуҗалыгын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры **Кузюров** Равил Әфраим улы, Республиканың төзелеш тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Евростиль» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайсин** Илнар Ленар улы, республиканың социаль-икътисадый үсешенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АКИБАНК» (гавами акционер җәмгыяте) акционер коммерциячел ипотека банкы идарәсе рәисе **Галәүтдинов** Илдар Хәйдәр улы, республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Фехтование буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Гыйлаҗева** Наилә Фәйзрахман кызы, республиканың оборона тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең 35 нче техник бүлеге инженер-конструкторы (схемалар техникы) **Сабиров** Тәлгать Ильяс улы, республикада кулланучылар кооперациясе системасын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасы идарәсе аппараты җитәкчесе **Тимерханов** Финзур Шакир улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әтисе
Валерий Александрович ШАДРИКОВның
вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры Александр Валерьевич Шадриковның авыр кайгысын уртаклаша.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Эт атучы

Бер кеше бик зур хыяллар белән юлга чыккан. Яшьрәк кеше булгандыр инде. Гадәттә, шуларның күңеле тулы хыял була бит инде. Яшәлгән еллар белән бергә хыяллар да кими бара. Ә моның кимемәгән. Ул үзен әкият каһарманы итеп тойган, кайсыдыр патшалыкта үткәрелгән ниндидер бәйгеләрдә җиңеп, тормышын көйләп җибәрү турында уйлаган. Алай гына да түгел, хан, патша, һич югы вәзир вазыйфасына ирешүгә дә өметләнгән. Кыскасы, хыяллары бик зурдан булган.

Ләкин моның шул зур хыялыннан башка, кесәсендә берни дә булмаган. Баштарак юлдан берәр нәрсә тапмаммы дип башын иеп барган. Алай да булмагач, тирә-ягына караштыргалаган – берәр җирдә миңа дигән байлык өеп куймаганнар микән дип. Алай да берни килеп чыкмагач, күккә карап атлаган – күктән дә юньле нәрсә килеп төшмәгән.

Аптырагач, бу зарланып та, елап та караган. Тик жәлләүче, ярдәм итүче табылмаган. Кайсыберәүләр башыннан сыйпап юаткан инде анысы. Тик башыңнан сыйпаудан гына тамак та туймый, өс тә бөтәйми икән. Шуннан егет бер нәрсәне төшенгән. Хыялыңа җитү өчен нәрсәдер эшләргә кирәк икән. Һәм бу эшләргә тотынган. Икмәк сорыйсы урынга эш сорарга гадәтләнгән.

Нәрсәдер эшли башлагач, моның тормышы беразрәтләнеп киткән. Адәм заты яшәгән төбәкләргә юлыкса, көнлекче булып ялланып тамак туйдырган, кием-салым юнәткән, кунар урын тапкан. Ә бер авылда озаграк тоткарланган, чөнки монда күбесенчә карт-корылар һәм хатын-кызлар яшәгән, шуңа күрә эш муеннан, хәлең генә җитсен.

Бу эшләгән. Җир казырга кирәк булса да, су китерергә дә, утын ярырга да, киртә-кура төзәтергә дә моны чакырганнар. Тырышкан инде бу кеше. Барысын да җиренә җиткереп, сыйфатлы итеп озакка сузмый эшләргә омтылган. Эшләгән саен, кулы шомарган, бөтен нәрсәгә дә маһир оста булып өлгергән.

Остарган саен, эшкә чакыручылар күбәйгән. Алар күбәйгән саен, кесәсе калынайган. Кесә калынайгач, үз йортын булдыру теләге туган. Һәм бу тагын да ныграк тырышып эшләргә тотынган. Моның турында ишетеп, күрше авыллардан да сорап килгәннәр. Үзенә күрә данлыклы остага әверелгән.

Шул рәвешле хәтсез генә мая туплагач, өй салырга тотынган. Агач кайтарткан бу, бура бурап куйган. Түбәсен япкан. Барысы да менә дигән килеп чыккан. Моның йорты авылда бер икәнне күргәч, хәзер моны өй салырга чакыра башлаганнар. Сүз ара сүз таралып, күрше авыллардан да чакырганнар. Шул рәвешле, бу өй салучы булып киткән. Эше авыр булса да, тормышы матурланган. Ә акча хәсрәте бөтенләй диярлек беткән.

Тик бер нәрсә үзегенә үтә башлаган. Бу авылда этләр бик күп икән. Һәм алар өрәләр икән. Элек алар өрмәгәннәрме, әллә вакыты бик тыгыз булып игътибар итмәгәнме, белмәссең. Мөгаен, алар хәзер генә, бу адәм ниндидер уңышка ирешә башлагач кына өрергә тотынганнардыр. Анысы да бик мөмкин.

Өстәвенә алар әле кеше тавышы белән өрәләр икән:

– Җитмәгәч җитми инде кешегә…

– Һи, оста булып йөргән була бит әле, кулыннан килсә-килмәсә дә…

– Кем иде бит безнең авылга килгәндә, ыштансыз бер хәерче иде.

– Безнең халыкны талап баеды инде, мескен.

Бу этләрнең шулай көн-төн өрүе теге адәмнең бик ачуын чыгарган. Һәм ул мылтык сатып алган. Бер эт тагын: «Халыкны талап баеды, авылдан куарга кирәк», – дип өрә башлаган икән, бу теге мылтыгыннан атып та җибәргән. Калган этләр качышып беткән, тик күпмедер вакыт узуга, тагын өрә башлаганнар. Бу чүкечен ташлап тагын мылтыгына үрелгән. Моны күрү белән этләр тагын юкка чыккан. Инде тынычланып эшкә тотындым гына дигәндә, бер көчек капка астыннан ләңгелдәргә тотынган. Бу тагын мылтыгын алып куа киткән. Куып тотып чәкегән моны.

Яңадан килеп эшенә тотынса, тагын бер көтү эт килеп өрергә тотынган. «Боларның барысын да атып бетермичә, котылып булмас», – дип уйлаган бу адәм һәм көне буе эт куып йөргән. Барысын да берәм-берәм чәкеп бетергән.

Инде икенче көнне эшкә тотыныйм дисә, башка этләр көтүе өрергә тотынган. Мылтыгын алып тагын эт куа чыккан. Ләкин боларны өркетү белән: «Туктале, болай итеп йөрсәм, мин бит остадан эт атучыга әйләнәм», – дип уйлап кире борылган. Шуннан соң, мылтыгын ташлап, эшкә тотынган. Этләр килеп җиткән инде, өргәннәр. Тик бу адәм борылып та карамаган, ә соңыннан колагы да өйрәнеп киткән. Этләр өрүе аның өчен черки безелдәве, чикерткә тавышы, яфраклар шыбырдавы кебек үк табигый бер күренешкә әверелгән.

Сәрия МИФТАХОВА

УЯНСЫН КУЯН!

Минзәлә

Минзәлә районының Куян авылында бүген 24 йорт исәпләнә, тик аның 15ендә генә яшиләр. Пропискада торучылар – 49. Кечкенә авылның планнары зурдан булып чыкты. Әмма хыялларны тормышка ашыру өчен юл кирәк. Калганын үзләре башкарып чыгарга җыена. Без аларның Куян елында ниләр өмет иткәнен белештек.

Тарихи мәгълүматлардан билгеле булганча, Куян авылына 1784 елда нигез салынган. 1795 елда анда – 67, 1959 елда – 372, 2005 елда 53 кеше яшәгән. Заманында Куян Бикбау авылының 5 нче бригадасы булып саналган. Элек куян, сарык фермалары эшләп торган. Бүген мәктәп, кибете булмаса да, медпункт, клуб-китапханәсе, мәдрәсәсе бар. Башлангыч мәктәп бер генә бала калгач ябылган. Авылда эш, юл юк, шуңа күрә яшьләр шәһәргә китә. Моңа аптырыйсы юк, хәзер күп җирдә шулай. Куянда 55–60 яшьтәге биш гаилә бар. Алар – иң яшьләре. Быел беренче тапкыр Авыл көнен уздырганнар. Йөзгә якын кеше җыелган. Мәрхүмнәрне дә онытмыйлар. Зиратны да бергәләп карап торалар.

Декабрист балалары

Куян авылы балаларын элек «декабрист балалары» дип йөрткәннәр. Бигрәк тә авыл кияүләре: «Сезгә ат һәм вертолет белән генә кереп була», – дип шаярткан. Хәзер дә хәлләр әллә ни үзгәрмәгән анысы. Тик юлны ачсалар, машиналар үтә ала.

– Безнең авылда яшәргә бик җайсыз, кызым. Иң авырткан җиребез – олы юлга чыгар өчен юл булмау. Яз-көз муеннан пычракка батабыз. Машиналар йөри алмый. Чирләп китсәң, кая барасың? Инде ничә елдан бирле район җитәкчелеге, юл салабыз, дип ышандыра. Хисап җыелышында, 2024 елга планлаштырабыз, диделәр. Өч мәртәбә җыйган үзара салым акчасына урамга таш салдык. Әле дүрттән бер өлешенә җитмәде. Авыл халкы гына түгел, читтә яшәүче авылдашлар да кеше башыннан 2,5 мең сум бирде. Авыл чатында тукталыш та кирәк. Җил-яңгырда басып торулары яман. Ә болай авылда яшәү рәхәт: газы, суы кергән. Бетерә генә күрмәсеннәр инде. Автокибет вакытында килеп тора. Өч кызым, оныкларым бар. Аллага шөкер, бик бай әби мин, – диде ялгыз яшәүче 68 яшьлек Хәмидә апа Бәдриева.

Хәмидә апа кайда гына хезмәт куймаган. Яшь вакытта фермада сарыклар караса, аннан Минзәләдә кабул итү пунктында эшләгән. Районнан авылга товарлар, кирәк әйберләр алып кайтып саткан. Итек басарга йон җыйган. Көнкүреш техникасын төзекләндерергә белгечләр чакырткан. Кыскасы, ике авылга хезмәт күрсәткән. Иминиятләштерү буенча агент, авылда клуб мөдире… Аннан соң Аюдан Куянга почта ташыган.

Буран гына чыкмасын…

Кечкенә авылда фельдшер булу – үзе бер бәхет. Вәзирә Гыйльмуллинаны бик яхшы белгеч дип мактыйлар. Куян һәм күрше Әхмәт авылы халкына медицина хезмәте күрсәтә ул. Җәяү дә йөри, ире машина белән дә илткәли. Куянда халык картаеп баргач, өлкәннәрнең өйләренә дә йөргәли.

Вәзирә монда 1996 елда Минзәлә районының Калморза авылыннан килен булып килгән. Төп йортта каената, каенанасы белән бик тату гомер кичергән. Аларның ризалыгын алгангамы, бик рәхәт яшибез, ди. Ире Рафил умарта тота. Бер кыз, бер ул үстергәннәр. Алар елларда кайтып, әтиәниләренең хәлләрен белешеп тора. Кечкенә авылда яшәвенә бер дә үкенми ул.

Әмма аны да юл мәсьәләсе борчый. Фельдшер булгач, җаваплылык дигән нәрсә бар бит. Буран чыга башласа, машиналарын тизрәк авыл башына чыгарып куялар икән. Дөнья хәлен белеп булмый, барысына да әзер булып торырга кирәк.

– Урамына ничек тә керерсең. Бикбау белән Куян арасындагы юлны хәл итсәләр, бик сөенер идек. Авылның киләчәккә өмете бик бәләкәй шул. Юл булса, кешесе дә артыр иде, әлбәттә, – ди 55 яшьлек Вәзирә Гыйльмуллина.

Тарих бүген языла

Нәзимә апа Галләмова Минзәләдә яши. Шәһәрдәге 3 нче мәктәптә башлангыч сыйныф укучыларын укыткан. Хәзерге вакытта лаеклы ялда булса да, балаларны шахмат серләренә өйрәтә. Куянга кайтып йөри. Мәрхүм ире, әтисенең йортларын тәртиптә тота. Куян авылы тарихын язарга хыяллана.

– Музей оештырырга йөрибез. Авыл халкы тарихи экспонатлар китерә. Ачык этнографик музей төзү турында хыялланам. Янында чәйханәсе дә булыр дип күзаллыйм. Мәктәп ябылгач, төзекләндереп, мәдрәсә ачтык. Җәй көне шунда авыл апаларына гарәп теле дәресләре оештырам. Түбән Камадан күрше Әхмәт авылына кайтучы Миңнулла хәзрәт Солтанов атна саен җомга намазлары үткәрде, вәгазьләр сөйләде. 100 мең сум грант откан идем, шул акчаны мәчет төзелешенә тотачакмын. Җәй көне эшне башларга иде исәп. Мәчет төзелсә, бәлкем, авылга күченеп кайтучылар да булыр иде, – ди 62 яшьлек Нәзимә апа.

Минзәләдә яшәүче Гөлшат Галәветдинова да авылы өчен җан атып йөрүчеләрдән. Кайчандыр математика укыткан ул. Сугышта һәлак булучылар истәлегенә төзелгән һәйкәлдәге исемнәрне яңарту, хаталарын төзәтү белән мәшгуль ул хәзер. Сугышта хәбәрсез югалган бабасын 13 ел эзләгән икән. Аның каберен табып, туганы белән Бөек Новгород якларына барып, рухына дога кылып кайткан.

– Юл булса, пенсиягә чыккач, авылга кайтыр идек, диючеләр бар. Казанда яшәүче сеңелкәшләремнең дә теләге бар. Гомумән, авылда әти-әниләренең нигезләрен яңарталар, ташламыйлар. Куян авылы бетмәс дип өметләнәбез, – ди Гөлшат Галәветдинова.

Куян авылы укытучыларга бай булып чыкты. Актанышта яшәүче, заманында математика укыткан Венера апа Гомәрова авылына атап «Рәнҗемә, авылым» дигән шигырь язган. Беткән авылларның барысының да язмышы чагыла анда.

Кайтып килдем әле Куяныма,
Аз гына вакытка булса да,
Каршы алды бөкерәйгән нигез,
Өзелергә торган бусага.
Авыл тып-тын, ятим йорт-куралар
Урам буйлап озатып калалар,
Рәнҗемәсәң иде, авылкаем,
Читтә гомер иткән балаңа.

БЕР РӘХӘТНЕҢ МЕҢ МИХНӘТЕ

ОЗЫН ЯЛЛАРДАН СОҢ ЭЛЕККЕГЕ РЕЖИМГА НИЧЕК КАЙТЫРГА?

Киңәш-табыш

Туйганчы йоклау, туйганчы ашау, туйганчы ял итү. Дүшәмбедән озын ялларга нокта куелды. Эшкә, укуга, элеккеге режимга ничек кайтасы? Тән-рух сәламәтлеген кайгырту турында белгечләрдән сораштык.

Бер көн генә җитмәс

Элеккеге режимга кайту турында кичә-бүген генә уйлыйсы түгел шул. Яхшы ял иткәннән соң ныгытып эшлисе барлыгын баштан чыгармаска да ярый инде дә, тик… Баш миен көтелгән яллар, сый тулы өстәл, якыннар белән уздыра торган кичләр биләп алгач, ни хәл итәсең? Белгечләр әйтүенчә, Яңа ел яллары бетәргә берничә көн кала элеккеге режимны кайтару турында уйлый башларга кирәк.

Университет клиникасының йокы лабораториясе җитәкчесе Лилия Шаһиәхмәтова искәрткәнчә, Яңа ел төнендә һәм аннан соң берничә көн үзеңә тулысынча ял бирергә ярый әле. «Эшкә чыгарга берничә көн кала күнегелгән режимнан чыгарга, эш режимына яраклаша башларга кирәк. Яту һәм уяну вакытларын көйләргә. Әгәр дә бәйрәм көннәрендә йокларга соң ятып, төш җиткәндә генә уяна торган булсагыз, моны үзгәртергә кирәк. Иртәрәк ятып, иртәрәк тора башлау хәерле. Организм сезне аңлаячак, элеккеге режимга ияләшә башлаячак», – диде КФУ белгече.

«Йокларга кирәк» дип кенә йоклап китеп булмаса, нишләргә?

– Вакытында йокыга китеп булмый икән, урамда йөреп керергә мөмкин. Мелатонин эчәргә була. Ул йокыны туйдырырга булышачак, – диде Лилия Шаһиәхмәтова. – Беренче эш көненә җитди эшләр, киңәшмәләр планлаштырмагыз. Эш графигына җиңел генә кереп китәргә кирәк бит. Беренче эш көне алдыннан, йокыдан торуга, пәрдәләрне киң итеп ачарга, бүлмәгә саф һава кертергә, физик күнегүләр ясап алырга, каһвә эчәргә киңәш ителә. Тагын бер әһәмиятле киңәш: кисәк сикереп торырга ярамый. Көнегезне баш авыртуы, кан басымы төшү, буыннар сызлау белән дәвам иттерүегез ихтимал.

Организм өчен D витамины да мөһим. Белгеч әйтүенчә, моның өчен кояш астында йөрергә кирәк. Организмны авыр ризык, хәмер белән тутыруны да туктатырга кирәк. Бу хәерлегә илтмәячәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балаларга килгәндә, аларга еллардан соң кабат хәл алу авыргарак туры килер. Чөнки аларның әле нерв системасы да тулысынча формалашмаган. Лилия Шаһиәхмәтова искәрткәнчә, гадәти режимнан тайпылуларын балалар көйсезләнү, киреләнү, ачу-ярсу белән күрсәтә. Шуңа да балаларга төнгә чаклы бәйрәм итүләр киңәш ителми.

Сорамагыз хәлләремне

Практик психолог Зөһрә Кәримова рухи хәлне дә кайгыртырга өнди.

– 7–10 көн ял иткәч, күпләргә «комфорт зонасы»ннан чыгу кыенга туры килер инде. Әмма эш ул – эш, аннан котылып булмый. Иртәме-соңмы, тәртәгә керергә туры киләчәк. Шуңа күрә «эшлекле кәеф»не кайтарырга кирәк. Әйтик, тагын биш көн эшлибез дә тагын ял итәбез, дип, үзеңә максат куярга. Организмны көчләп түгел, кечкенә адымнар белән укуга, эшкә ияләштерә башларга. Көн дәвамында башкара торган эшләрне язып куярга, көн тәртибенә вак-төяк мәсьәләләрне һәм хәл итәсе мәшәкатьләрне әкренләп кертергә. Баш миен активлаштыру өчен, хәрәкәт кирәк. Урамда күбрәк йөрергә тырышыйк, – дип киңәш итә белгеч. – «Мин ялкау», «Кулымнан эш килми» дип, үзеңне һич кенә дә тәнкыйтьләргә, сүгәргә ярамый. Бу – табигый, гадәти хәл. Шунысы да мөһим: артыгын тырышып, бер көнгә күпләп эш өймәгез. Бу төшенкелеккә дә китерергә мөмкин. Бөтен яктан җиңелрәк булсын өчен, спорт белән шөгыльләнүне гадәткә кертергә кирәк. Әгәр инде эш режимына кайту чыннан да бик авырдан бирелә икән, психологларга мөрәҗәгать итмичә булмас.

Чамасын белеп кенә

Елларда баш та, тән дә ял итә. Берничә көнлек тәнәфес мускулларга да тәэсир итми калмый, билгеле. Фитнес-тренер Анна Мотина искәрткәнчә, спорт белән шөгыльләнүгә акрынлап кайтырга кирәк.

– Йөрәк һәм буыннарны саклау мөһим. Шуңа да күнекмәләр бик җитди, интенсив булырга тиеш түгел. Әйтик, беренче көнне җиңелчә генә күнегү ясарга, тора-бара күләмен арттырырга мөмкин бит. Спорт белән дус булганнарга элекке режимга кайту җиңелрәк, билгеле. Әгәр дә елларда активлык күрсәтмичә, кырын яткан булсагыз, сулыш, йөрәк-кан тамырлары системасын яңадан әзерләргә кирәк булыр. Күнекмәләрне йога, боди-балет, җиңелчә кардиодан башларга киңәш ителә, – ди белгеч.

Тамак хакы

Елларда аз ашалмагандыр, билгеле. Диетологлар «разгрузочный день», ягъни организмга ял биреп ашау көнен оештырырга тәкъдим итә. Иң дөресе – калорияле ризыкларны киметү. Гарнир буларак яшелчәләр куллану, көннең беренче яртысында җиләк-җимеш ашау хәерле. Көн дәвамында җитәрлек күләмдә су эчү турында онытмаска. Ашаган һәр килокалория өчен организмга 1 мл сыеклык кирәк.

Моннан тыш, авырлыктан котылам дип, һич кенә дә ач тору, махсус эч йомшарта һәм сидек кудыра торган дарулар кулланырга ярамый.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 17064 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 202

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+